СЫНАТМАДЫК

Авыл хуҗалыгы тармагы эшчәнлеге нәтиҗәсе: 3,6 млн тонна бодай, 2,2 млн тонна сөт

> 2

ӨМЕТ ЯШӘТӘ

Баласын көткән һәр әнинең уллары исән-сау кайтсын иде

> 3

ГҮЗӘЛ ГАЗЕТДИНОВА:

«Укытучылар нәселеннән булгач, «бишле»гә генә укырга туры килә

> 4

КЕЛӘМ КҮРСӘТЕР

Газетабызның көрәш бәйгесендә кайсы команда беренче урынга чыгар?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 14 (29174) | Чәршәмбе | 31 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Эльвира ВӘЛИЕВА

УРТАК БУРЫЧ

Хәрби хезмәт

Былтыр Татарстанда 9 меңнән артык кеше контракт буенча хезмәт итү өчен килешү төзегән. Республикада хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларына киң колачлы ярдәм чаралары гамәлдә. «Узган елгы бурычлар саклана», – диделәр контракт буенча хезмәткә багышланган матбугат очрашуында.

«Татар-информ»

Раил Гарифуллин (исеме үзгәртелде. – **Ред.**) бер елга якын контракт буенча хезмәт итә.

– Мине кечкенәдән шулай тәрбияләделәр: ир-ат үз гаиләсенә, иленә, Ватанына тугры булырга тиеш, – ди ул. – Махсус хәрби операция игълан ителгәч тә, хәрби комиссариатка бармакчы идем, ул вакытта гаиләм каршы килде. Солдат каешы буа алмагач, йөрәк янды инде. Тора-бара өйдәгеләрне ризалаштырдым. Башкача була да алмый, танышларым-дусларым яу кырында булганда, мин ничек өйдә ятыйм ди? Ил өстенә килгән авырлыкны бергә күтәрергә кирәк. Монда ватанпәрвәр булмаган кеше юк. Без барыбер җиңү белән әйләнеп кайтачакбыз. Гаиләләребез өчен дә җан тыныч, аларга төрлечә ярдәм итәргә тырышалар. Әле күптән түгел генә кызым спектакльдән фото төшереп җибәргән иде. «Батыр» картасы белән бушка ял итеп кайткан.

Контракт буенча хезмәткә сайлап алуның Казандагы пункты җитәкчесе Евгений Токмаков әйтүенчә, 2023 елда Татарстан хәрби комиссариатлары аша 9 меңнән артык кеше контракт буенча хәрби хезмәт итү өчен килешү төзегән. Хәрби хезмәткә китү турында карар кабул итүчеләр арасында республикада яшәүчеләр белән беррәттән, илнең башка төбәкләрендә теркәлүчеләр һәм чит ил гражданнары да бар. «Соңгылары – нигездә БДБ илләреннән килүчеләр», – дип тә ачыклык кертте Евгений Токмаков «Татар-информ» агентлыгында узган чарада.

Илебез сагына гүзәл затлар да китә. Дөрес, Евгений Токмаков килешү төзүчеләрнең күпмесе хатын-кызлар икәнне төгәл әйтә алмады. Аларның медицина өлкәсендәге белгечләр булуын гына искәртте.

– Махсус хәрби операция зонасына китүчеләр белән чагыштырганда, контракт буенча килешү төзергә дип килүче гүзәл затлар күбрәк. Әмма нинди шартларда эшләргә һәм яшәргә туры киләчәген аңлата башлагач, кире уйлыйлар, – диде Казандагы пункт җитәкчесе.

Евгений Токмаков сүзләренә караганда, быел Татарстанда контракт нигезендә хезмәт итүчеләр өчен былтыр гамәлдә булган түләүләр үз көчендә калачак.

– Хәрбиләр илнең Оборона министрлыгыннан бер тапкыр бирелә торган – 195 мең сум, ДОСААФтан 105 мең сум түләү алачак, – диде ул. – Моннан тыш, муниципаль берәмлекләр һәм предприятиеләр тарафыннан да аерым түләүләр каралган. Гомумән алганда, бер тапкыр бирелә торган түләү 600 мең сумга кадәр җитәргә мөмкин. Айлык һәм өстәмә түләүләр дә бар.

Евгений Токмаков Татарстанда контракт нигезендә хезмәт итүчеләргә бер тапкыр бирелә торган түләү мәсьәләсендә дә ачыклык кертте.

– 305 мең сум күләмендәге акчаны ике категориягә караган хәрбиләр алырга хокуклы. Беренче категориягә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Татарстан территориясеннән мобилизация буенча чакырылган кешеләр керә. Икенчесенә хәрби хезмәткә чакыру буенча алынып, контрактны Татарстандагы хәрби комиссариатларда яки республикада урнашкан хәрби частьларда төзегән кешеләр карый. Контрактның 2023 елның 31 августыннан соң төзелгән булуы шарт, – диде ул.

Билгеле булганча, әлеге төр түләү республикада 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә иде. Ел азагында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов аны озайту турында карар кабул итте.

Контракт буенча хәрби хезмәткә нинди авырулар белән алмаулары да билгеле.

– Туберкулез, ВИЧ, сифилис, В һәм С гепатитлары кебек социаль куркыныч тудыра торган авырулары булган кешеләр белән контракт буенча хәрби хезмәткә килешү төземәячәкләр, – диде Евгений Токмаков.

Контракт нигезендә хәрби хезмәт узу мәсьәләләре буенча барлык мәгълүматны 117 телефон номеры яки heroes-tatarstan.ru сайтыннан белешергә мөмкин.

АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮЛӘР

Бер тапкыр **195000** сум *(килешүне бер ел һәм аннан да озаграк вакытка төзегән очракта)*

Махсус хәрби операция зонасында аена **204000** сумнан башлап *(хәрби дәрәҗәсе, вазыйфасы һәм хезмәт итү елына карап)*

	Бер айга түләү
Укчы	204000+
Пешекче	211000+
Машина йөртүче	211000+
Гранатометчы	211000+
Пулеметчы	211000+
Өлкән машина йөртүче-электрик	216000+
Өлкән сапер	216000+
Өлкән телефонист	219000+
Команда-штаб машинасының радиостанциясе җитәкчесе	226000+
Штаб инструкторы	226000+
Отделение командиры	232000+
Отделение командиры – взвод командиры урынбасары	242000+

Күзәтүчесез булмый

Март аенда Россия Президентын сайлауда чит илләрдән 500–1000 чамасы күзәтүче катнашачак. Үзәк сайлау комиссиясе башлыгы Элла Памфилова әйтүенчә, күзәтүчеләр 100дән артыграк илдән киләчәк.

Үзәк сайлау комиссиясе 95 илгә чакыру җибәргән. Алардан уңай җаваплар алына. Сайлауда кимендә 13–14ләп халыкара оешма вәкилләренең дә катнашуы күздә тотыла. Моннан тыш 20 илдән Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең килүе көтелә.

«Президент сайлауга бик зур кызыксыну күрсәтүләрен сизеп-күреп торабыз», – дигән Памфилова. Шулай ук бәйсез халыкара күзәтүчеләргә дә чакырулар юлланган.

Уттан калмый

Республикада 22–28 гыйнвар чорында коткаручыларга 223 тапкыр тревога буенча юлга кузгалырга туры килгән. Шул исәптән алар 64 тапкыр янгын сүндерергә барган. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, янгыннарда 3 кешенең гомере өзелгән, 5 кеше төрле дәрәҗәдә җәрәхәтләнгән. Янгын сагы хезмәткәрләре 3 кешене үлемнән коткарып калган.

Электр приборларыннан (21 очрак), мичләрдән (11) файдалану кагыйдәләрен бозу, ут белән саксыз эш итү (15 очрак) фаҗигане төп сәбәпләренә әйләнгән. Калган 7 очрак башка сәбәпләргә бәйле.

Йөртүче өчен түгел

ЮХИДИ рульдә утырган кешенең телефоннан сөйләшүе нәрсәгә китерергә мөмкин булуын искә төшерде.

Һәр ел саен юлларда меңнәрчә кеше һәлак була яки җәрәхәтләнә. Моның төп сәбәбе башлыча кешенең үзенә бәйле. Әйтик, рульдә барганда телефоннан сөйләшү бик аяныч тәгәлләнергә мөмкин. Мондый очракта йөртүченең уяулыгы кимегәнлектән, авариягә эләгү куркынычы бермә-бер арта.

ЮХИДИ белгечләре киңәш иткәнчә, телефон шалтыраган очракта, куркынычсызрак урында туктап сөйләшергә яки телефонны кулга тотмыйча гына сөйләшү мөмкинлеге бирердәй җайланмадан файдаланырга кирәк. Сүз уңаеннан, телефоннан сөйләшеп барган йөртүче 1500 сум штрафка тартылырга мөмкин.

vk.com

Өч көн ял

Февраль аенда, Ватанны саклаучылар көне билгеләп үтелү сәбәпле, атнасына биш көн эшләүчеләрне кыска эш атнасы көтә. Быел 23 февраль җомгага туры килә. Шуңа күрә, алдагы елларны да исәпкә алып, тоташ 3 көн: 23, 24 һәм 25 февральдә ял итәчәкбез. 22 февральдә исә эш көне 1 сәгатькә киметелә.

Ахыры күренми

Узган атнада – 22–28 гыйнвар чорында Татарстанда 383 кеше коронавирус йоктырган. 108 сырхауны хастаханәгә салганнар. «Объясняем.рф» порталы мәгълүматларына караганда, тулаем Россия буенча шушы чорда 24288 кешенең ковид ияртүе ачыкланган. 2924 сырхау хастаханәгә салынган, 111е вафат булган.

Шул ук вакытта республикада грипп һәм ОРВИ йоктыруның 16,9 мең очрагы теркәлгән. Белгечләр әйтүенчә, Татарстанда эпидемия сезоны тәгәлләнмәгән әле. Ул грипптан чирләүчеләр кимегән очракта гына тәмамланачак.

Илкүләм проектлар

Кунакчыллык бәһасе

1,7 млрд сум. 2022–2024 еллар арасында Татарстанга кунакларны җәлеп итү, аларга уңайлы мохит тудыру өчен тотылган акча күләме бу. «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проектын тормышка ашыру нинди нәтиҗәләр биргән һәм бу акча нәрсәгә тотылган? Кунакчыллык өчен җаваплы кешеләр шул хакта хисап тотты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Саннарга күз салсак, илкүләм проект максатларына 2022 елда – 530 млн, 2023 елда 817 млн сум акча тотылган. Быелга исә 419 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов әйтүенә караганда, илкүләм проектның максатлары – кунакханәдәге урыннар, тармактагы кадрлар санын күбәйтү, туристик юнәлешләрне арттыру, Россия һәм республика икътисады үсешенә өлеш кертү.

Илкүләм проектны тормышка ашыру дәверендә дәүләт ярдәме белән Татарстанда глэмпинг төзелеше дә күзгә күренеп диярлек үсте. Төзелеш өчен субсидияне республиканың 31 проекты алган. Акча теле белән әйтсәк, 521 млн сум матди ярдәм дигән сүз бу.

Илкүләм проект ярдәме белән коену өчен урыннар (пляж) да артты. Казанда гына түгел! Сүз республиканың башка район-шәһәрләре турында да бара. Барлыгы 22 проектка 173,6 млн сум акча бүлеп бирелгән. Димәк, 2024 елгы җәйге сезонда коену өчен мөмкинлекләр күбрәк булачак.

Моннан тыш илкүләм проект кысасында республиканың ике шәһәре (Казан һәм Алабуга) «Шәһәр үзәгенең туристик коды» программасына кергән. Бу шәһәрне төзекләндерү, тагын да матуррак итү өчен мөмкинлекләр биргән. Сергей Иванов сүзләренчә, ике шәһәргә 378,7 млн сум акчалата ярдәм күрсәтелгән. Мондый ярдәм чарасы илнең 30 шәһәренә генә эләккән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– Төбәкләрдә эчке туризмны үстерү гаять мөһим булып тора. Туризм тармагын нәтиҗәле, сыйфатлы итеп үстерү өчен Россиядә барысы да бар. Болар – тарихи, мәдәни, табигый байлыкларыбыз.

Сүзгә-сүз

Эльвира НӘБИУЛЛИНА, Россия Үзәк банкы башлыгы:

Ташламалы ипотека халыкның торак сатып алу мөмкинлеген арттыру бурычын хәл итми. Киң колачлы ташламалы программалар өчен башка салым түләүчеләр, әлеге ташламалардан файдаланмаучылар түли. Шуңа күрә мондый төр программалар адреслы булырга тиеш, мәсәлән, гаилә, авыл, Ерак Көнчыгыш ипотекасы.

(«Коммерсант» басмасыннан)

РОССИЯДӘ – ТОРАК

41 МЛРД КВ. М



37 % >> кирпеч йортлар
23 % >> панель йортлар
16 % >> агач йортлар
7 % >> блок йортлар

*Росстат мәгълүматлары буенча

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПАРИЖ – КАМАЛЫШТА, ПАКЬСТАНДА – КОРАЛЛЫ ФЕТНӘ

Дөньякүләм турбулентлык тарихи рекорд куюын дәвам итә. АКШның Дәүләт секретаре Блинкен Якын Көнчыгыш турында: «Безнең беркайчан да төбәктә мондый куркыныч вазгыять күргәнебез юк иде», – ди.

Аның сүзләрендә хаклык зур, әмма киеренкелек Якын Көнчыгыш белән генә чикләнми. Европа һәм Америка үзләре дә турбулентлык зонасында. Европа фермерларының протест акцияләре көннән-көн киңрәк җәелә. Немец һәм француз фермерларына континентның барлык илләрендә дә диярлек кушылдылар. Чикләр ябыла, трассалар бикләнә. Дүшәмбе көнне Франциянең барлык почмакларыннан тракторлар Парижга юл тотты. Кичке сәгать җиде тулганда, Парижга илтә торган күпчелек автомагистральләр фермерлар тарафыннан бикләнгән иде. Протестка такси йөртүчеләр дә кушылды. Илнең әчке эшләр министры: «Безне авыр атна көтә», – дип белдерде. Хөкүмәт башлыгы вәгъдә иткән ташламаларны баш күтәргән авыл халкы кире какты, таләпләрнең тулысынча үтәлүен сорыйлар. Февральдә Европада язгы кыр эшләре башлана. Хөкүмәтләр, фермерлар дулар-дулар да, эш сезоны башлангач, басуларга кайтып китәр, дигән ышерен өмет белән яна. Каршы як исә көрәшнең яшәү-үлем хакына баруын яхшы аңлый һәм кайнарлык температурасын үстерү ягында.

Көнбатыш элиталары, халыклар игътибарын Якын Көнчыгыштагы вакыйгаларга юнәлтеп, үзләрендәге проблемаларны онытттыру максатын туктатмый. Вашингтон Иранга хәрби җавап планнары әзерли. Масштаблы ут ачу проблеманы хәл итмәячәк, билгеле, кискенләштерәчәк кенә. Әмма төбәктә берничә кайнар нокта барлыкка китерергә тырышучылар бар. Сишәмбегә каршы төндә Пакьстан армиясе белән Бәлуҗистанны азат итү төркеме сепаратчылары арасында аяусыз сугышлар барды. 15 мең кеше яши торган Мач шәһәре фетнәчеләр кулына күчте, диделәр. Рәсми хакимият куркынычсызлык көчләренең һөҗүмне кире кагуы турында белдеру ясаса да, социаль челтәрләр һаман да каты сугышлар баруын хәбәр итә. Пакьстан армиясенең бик күп солдаты әсирлеккә төште дигән сүзләр йөри.

Кытай кризисы да спираль бөтерүен дәвам итә. Гонконг суды Кытайның иң зур төзелеш гиганты China Evergrande Groupны банкротлыкка чыгару турында карар кабул итте. Компаниянең өметсез хәлдә булуын без берничә ел элек язган идек һәм, ниһаять, финал сәгате сукты. Компаниянең акцияләре шунда ук зур мәтәлчек атты, Гонконг фонд биржасы сәүдәне туктатырга мәҗбүр булды. Пекин, фонд базарын торрыкландыру өчен, 300 миллиард доллар акча бүлеп бирде. Хөкүмәт акчасы безнең базарны озак тереп булмаячак. Игътибар итик: бөлгән компаниянең җәяте шуның кадәр иде.

Россиядә

РОССИЯ АРКАСЫНДА – КЫТАЙ ПЫЧАГЫМЫ, ЯКИ ГАЗНЫ КАЯ КУЯРГА?

Масштаблы хәрби хәрәкәтләр алып баруга һәм тиңе булмаган санкцияләр астында яшәүгә карамастан, Россиянең финанс хәле чагыштырмача яхшы. Планетакүләм киеренкелек углеводород бәяләрен түбәнгә китүдән саклый. Киеренкелек үзе начар нәрсә булса да, нефть бәясенең 80 доллар тирәсендә тирбәлүе – федераль бюджет өчен бик кулай күренеш.

Әмма чимал сату проблемалы мәсьәлә булып калуын дәвам итә. Федераль хөкүмәт вице-премьеры Александр Новак илнең Европага газ сатарга әзер торуын белдерде. 2024 елда газ транзиты буенча Россия – Украина килешүенең срогы чыга. Бу хәзер Көнбатышка торба газ сату буенча бердәнбер диярлек маршрут булып тора. Мәскәү газны Украина аша озатырга да риза, башка маршрутларга да каршы түгел. Европалылар гына теләк белдерсен. Әмма: «Без әлегә андый теләкне күрмибез», – ди вице-премьер.

Сер түгел: махсус хәрби операция башланганнан соң иң зур зыянны «Газпром» күрде: бик күп табышын югалтты ул. Баштарак, зәңгәр ягулык агымнарын Көнчыгышка борабыз, дип дөмбер каккан идек, ул проблемалы булып чыкты. Кытайга таба «Себер куәте – 2» торбасы биел сузыла башларга тиеш иде, әмма «Financial Times» газетасы тәзелешнең соңгарак күчерелергә мөмкин икәнен яза. Бер елга 50 миллиард кубометр газ куачак торба әле һаман да сөйләшүләр объекты гына булып калуын дәвам итә. Монголия Премьер-министры Лувсаннамсрайн Оюун-Эрдэнэ, Кытай һәм Россия яклары проектның икътисадый файдасы турында сөйләшүләр алып баралар, ди. Аңлашыла инде: Пекинга арзанга кирәк, Россия ягы үзкыйммәттән дә түбәнрәк бәягә сата алмый. Бәхәскә кайчан нокта куелып, кайчан эшкә керешелер, әлегә мәгълүм түгел. Мөгаен, газны кубрәк эчке базарда һәм югарырак бәядән сатарга туры килер. Эчке базарда тарифларны югарырак күтәрү турында сүзләр ишетелә.

Газны гына түгел, электр энергиясен сату да мәшәкатьле әле монда. 2023 ел йомгаклары буенча электр энергиясе экспорты 21 процентка кимегән. Сәбәбе: Европага таба ток акмый башлаган. Экспортның төп юнәлешләре булып Азия илләре калган. Казахстан – 4,7 млрд кВт/сәгать, Кытай 3,1 млрд кВт/сәгать электр энергиясе сатып алган. Өченче урында – Монголия.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК – АВЫЛНЫ ЯШӘТҮЧЕ

Терлекләрне максатчан киметүне туктатырга, ферма ишекләренә кадак кагарга ашыкмаска, санны гына түгел, нәтиҗәлелекне дә кайгыртырга. Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының еллык коллегиясендә куелган бурычларның берничәсе генә бу. Әйтергә кирәк, ул шактый «кызу» һәм анализлы иде. Уңышларны санап узудан бигрәк, авырткан урыннар турында да сөйләшү булды. Газетабызның киләсе саннарында коллегиядә күтәрелгән мәсьәләләргә кабат тукталырбыз әле. Әлегә – иң актуальләре.

Җитештерү

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров фикеренчә, узып киткән ел авыл хуҗалыгын ныклыкка сынады: корылык булды, сәнәгать продукциясенә, төзелеш материалларына бәяләр артты, кредитлар кыйммәтләнде һәм болар барысы да авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр төшү белән бергә үрелеп барды.

Ул җитештерү индексының 92,1 процент тәшкил итүен, терлекчелек алга китү аркасында тулаем продукция күләменең соңгы еллардагы уртача күрсәткеч дәрәҗәсендә калуын әйтте. Республика ил төбәкләре арасында бишенче урынны саклап кала алды.

– Без республика халкын төп продукция белән тулысынча тәэмин итәбез. Төп бурычыбыз – без өйрәнгәнчә, җитештерү күләмен генә арттыру түгел, ә беренче чиратта аграр тармакның нәтиҗәлелеген арттыру, – дип басым ясады министр.

Сан

➤ Узган ел, 2022 елга караганда, **7,5 процентка** күбрәк сөт савып алынган. Продуктивлык **648 килога** артса да, бер сыердан савып алына торган сөт күләме буенча без Россиядә бары тик 35 нче урында гына торабыз.

➤ Иң күп сөт савып алган районнар: Кукмара, Балтач, Әтнә, Саба һәм Мамадыш. Әлеге районнарда республика сөтенең **35 проценты** савып алына. Соңгы биш елда Бөгелмә, Минзәлә һәм Мөслим районнарында да сөт саву күләме күзгә күренеп арткан.

➤ Терлекләр иң күп кимегән районнар: Яңа Чишмә районында – **10 мең**, Кама Тамагында **8 мең** баш сыерга кимегән. Ә Спас районында – барлык терлекнең **50**, Чирмешән районында **20 проценты** юк ителгән.

Хезмәт хаклары

Министр әйтүенчә, дәүләт ярдәмен исәпкә алып, рентабельлек 8,9 процентны тәшкил итә, ә аннан башка 3 проценттан азрак. Табыш белән эшләүче авыл хуҗалыгы предприятиеләре 1,7 процентка кимегән.

– Бер яктан караганда, аңлашыла да. Бу инвестицияләр җәлеп итү һәм объектларның тиз генә үз-үзләрен аклавына бәйле. Чыгымнар да артты. Шул ук вакытта хуҗалыкларның үзләренең эчке резервлары күп. Без үзебезнең уңышсызлыкларыбызда һава торышын һәм базарны гаепләргә гадәтләндек, ләкин идеаль һава торышының һәм базарның бервакытта да булганы юк – алар ничек бар, шулай. Авыл хуҗалыгы продукциясенә югары бәя булыр дип өметләнмәгез, без үзебезнең иң яхшы хуҗалыкларның үзкыйммәте кысасында эшләргә өйрәнергә тиеш, – диде Марат Җәббаров.

Уңышлы хуҗалык булу өчен, эшчеләрне дә кызыксындыра белергә кирәк. Министр сүзләренчә, соңгы биш елда хезмәт хаклары буенча шактый алга китеш сизелә. Бүген ул, ике тапкыр артып, уртача 46,8 мең сумны тәшкил итә.

– Ләкин эшлисе эшләр бар әле, без республикадагы уртача хезмәт хакларына якынаерга тиешбез, – диде ул.

Терлек саны кимү

2023 елда авыл хуҗалыгы оешмаларында мөгезле эре терлекләр саны 3 процентка, ягъни 19 мең башка кимегән. Тискәре динамика 27 районда күзәтелә.

– Узган елларда без терлекләрне сәламәтләндердек, авыру, аз сөт бирә торган сыерларны юк иттек. Шулай ук соңгы өч елда республикага токымлы 51 мең тана алып кайттык, – диде Марат Җәббаров.

Тик терлекләрнең санын максатчан киметкән хуҗалыклар да бар. Алар: Яңа Чишмәдәге «Агро-Основа» һәм Козлов крестьян-фермер хуҗалыгы, Буадагы «Заря», Апастагы «Мол Апас», Азнакайдагы «Марс», Актаныштагы «Тамыр», Актаныш, Биектаудагы «Серп и Молот» хуҗалыклары.

– Терлекләр санын киметеп, без бу авылларның киләчәген куркыныч астына куябыз. Башлыкларга һәм инвесторларга мөрәҗәгать итәм: сезнең артыгызда бөтен бер территорияләр, һәм сезнең социаль җаваплылык шулай ук югары. Терлекчелек фермалары – авыл халкы өчен төп эш урыны. Малларның баш санын киметеп, без әлеге авылларның киләчәген шик астына куябыз, – дип басым ясады Марат Җәббаров һәм район башлыкларына, инвесторларга фермаларга эзне суытмаска кушты.

Кош ите һәм йомырка

Марат Җәббаров узган ел ахырында аеруча актуаль булган һәм телдән төшмәгән кош ите һәм йомыркага кагылышлы вазгыятькә дә тукталды.

– Ит җитештерү 2022 ел дәрәҗәсенә 13 мең тонна җитми калды, шуның 10,8 мең тоннасы кош итенә туры килә. Бу «Чаллы-Бройлер» кошчылык фабрикасында җитештерү күләмнәре кимү аркасында килеп чыкты, хәзер анда моның буенча эш алып барыла, – диде ул.

Ә менә йомыркага булган ихтыяҗның тулысынча канәгатьләндерелүен әйтте. Аның белән тәэмин ителеш – 129 процент. Узган ел җитештерү 2 процентка арткан, быел да бу күләмнәрнең саклап калыначагын хәбәр итте.

Ферма бетсә, авыл бетә

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында терлекчелек начар үсеш алган районнарда халыкның кимүенә басым ясады.

– Терлекчелек юк икән, димәк, эш тә юк. Эш юк икән, димәк, халык китә. Бер киткән белгечләрне кире кайтару бик авыр булачак. Ферма эшләми икән инде, мәктәбе, кибете дә ябылачак. Һәм биш елдан авыл булмаячак, – дип, күпләрне борчыган мәсьәләгә тукталды.

Ул район башлыкларына әлеге проблемаларны чишү юлларын уйларга кушты. Рәис фикеренчә, әгәр фермалар эшләми икән, аларны нәтиҗәле эшләтеп җибәрү өчен, инициативалы кешеләрне, шәхси эшмәкәрләрне эзләргә кирәк.

Рөстәм Миңнеханов чималны сатып алу бәяләренә дә тукталды. Аның фикеренчә, авыл хуҗалыгы продукциясен, бигрәк тә сөтне сатып алганда монополизациягә урын булырга тиеш.

– Күршеләрдә һәм бездәге бәяләрне күзәтергә кирәк. Әгәр без бәяләрне контрольдә тотмасак, шәхси хуҗалыкларда бернинди дә терлекчелек булмаячак, – диде ул.

СҮЗ УҢАЕННАН. Утырыш башланганчы, Рөстәм Миңнеханов Марат Җәббаров һәм башка рәсми затлар белән бергә эре габаритлы техника күргәзмәсен карады. Шулай ук үзмәшгульләр, фәнни оешмалар һәм фермер, шәхси хуҗалыкларның продукциясе тәкъдим ителгән экспозиция белән танышты.

«ТатАгроЭкспо» агросәнәгать комплексы казанышларының VI махсуслаштырылган авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә Россиядән 200дән артык компания катнашты. Биредә терлекчелек, игенчелек өчен авыл хуҗалыгы техникасы, җайланмалары һәм чимал, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү, саклау һәм тәрәккый өчен җиһазлар тәкъдим ителгән иде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КИЛӘЧӘКНЕ САЙЛЫЙБЫЗ

Дәүләт Советында

Быел 5–17 февральдә мәктәпләрдә узачак «парламент дәресләре» «Киләчәкне сайлыйбыз» дигән темага багышлана. Анда Россия һәм Татарстанның сайлаулар системасы нигезләре турында сөйләшәчәкләр. Шул уңайдан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламентта тарих, җәмгыять белеме укытучылары белән очрашты.



tatarstan.ru

Билгеле булганча, әлеге проект республикада 16 нчы мәртәбә үткәреләчәк. Укучылар парламент дәресендә катнашып кына калмыйча, инша язып, видео төшереп, рәсем ясап, иҗади бәйгедә дә үз сәләтен сынарга мөмкин. Нәтиҗәсен исә апрель аенда Россия парламентаризмы көне уңаеннан Дәүләт Советында узачак чарада белербез.

– Проект кысасында республикада ел саен укытучылар белән очрашу гадәте барлыкка килде. Республика белем һәм тәрбиягә җитди өлеш керткән менә дигән укытучылар эшли. Нәкъ менә сез Татарстанның киләчәк үсешенә нигез саласыз. Яшь буынга дөрес юнәлеш биреп, гражданлык узаңын формалаштыруга ярдәм итәсез, – диде парламент рәисе.

Дәреснең темасы юкка гына сайлауларга багышланмый. Ни өчен дигәндә, 15–17 мартта – Россия Президентын, сентябрьдә Дәүләт Советы депутатлар сайлау узачак. 2025 елда исә Татарстан Рәисен сайлау көтелә. Шуңа күрә дәресләрдә сайлау системасы, кеше хокуклары турында сөйләшәмәкчеләр.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Россия Президентын сайлау – иң мөһим вакыйга. «Без илебез лидерын сайлап, Россия үсеше этапларын билгеләп үтәчәкбез. Бу – барыбыз өчен дә имтихан», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин бигрәк тә 18 яше тулган яшь сайлаучылар белән эшләүгә игътибар бирергә кирәклегенә басым ясады. Яшь сайлаучыларга аларның хокук һәм бурычларын аңлатырга кирәклеген әйтте. Республиканың Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматларына караганда, Россия Президентын сайлауда беренче тапкыр 90 мең кеше тавыш бирәчәк. Фәрит Мөхәммәтшин Россиядә игълан ителгән Гаилә елында сайлауга гаилә белән бергәләп килүне дә хуплады.

Әлмәт шәһәрендәге «Адымнар» һәм Сәләт мәктәпләрендә җәмгыять белеме укытучысы Гөлнара Гатауллинаның дәресе гади генә үтмәячәк. Ул чын сайлау участогына әйләнәчәк.

– Фәрит Хәйруллович чыгышын тыңлаганда, парламент дәресен күз алдыма китереп утырдым. Сыйныфымдагы укучыларны берничә төркемгә, ягъни аерым партияләргә бүләчәкмен. Һәркайсы Президентлыкка үз кандидатурасын тәкъдим итәчәк. Сайлау комиссиясе булачак. Яшерен, онлайн сайлау төрләрен аңлатачакмын. Күп кеше әле боларны аңлап та бетерми, – ди Гөлнара Гатауллина.

> Тарих һәм җәмгыять белеме фәннәрен яхшылап өйрәнмәгән буын да бар. Кайберәүләр хәтта Конституцияне, аның эчтәлеген белми. Шуңа күрә балалар аша әти-әниләргә аңлату эшләре алып барсак, файдалы булыр иде.

Мин укучыларыма: «Әти-әниләрегезгә Конституциядәге хокуклар, Президентның вәкаләтләре турында сөйләгез», – дип аңлатам.

Гөлнара Гатауллина җәмгыять белемен тормышта иң кирәкле фәннәрнең берсе дип саный. Ул икътисад, сәясәтне, социаль өлкә, мәдәниятне һәм башка темаларны үз эченә ала. Тик атнага бер дәрес белән генә ерак барып булмый шул. Шуңа күрә укучыга дәрестән соң өстәмә шөгыльләнергә туры килә.

Гүзәлия Габделвәлиева Чаллы шәһәрендәге 2 нче гимназиядә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәрен укыта. Шул ук вакытта мәктәптә тарих укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе дә әле ул. Парламент дәресенә укучысы – Дәүләт Советы депутаты, Казандагы халыкара мәктәп директоры Нияз Гафиятуллинны чакырмакчы.

– 2005 елда туган балаларга быел 18 яшь тула. Кечкенә чактан ук үз иленең патриоты булсын өчен, без, укытучылар да, укучыларга дөрес итеп аңлата белергә тиеш. Сайлауда катнашам, мин әле – күзәтүчеләр төркеменең җитәкчесе дә. Без бер ай дәвамында тырышып эшләячәкбез, – ди 30 ел стажлы укытучы.

Сәрия МИФТАХОВА

БЕР ҖЫЛЫ СҮЗ ҖИТӘ

Ватан хакына

Апаста яшәүче Ранис Җамалиев кечкенәдән курку белми. Әнисе Резедә апа әйтүенчә, ул спортта да, укуда да алдынгы була.

– Улым батыр йөрәкле. Чечнядә алты ай хезмәт итеп кайткан бала ул. «Без бармасак, Ватанны кем саклар?» – дип кенә тора. Туктатмасам, әллә кайчан үз теләге белән китә иде инде. 60 яшьлек юбилеем узганчы гына түз инде, дидем. Сүземне тыңлады. Туган көн узгач, контракт төзеде, – ди Резедә апа.

Ранис каләмдәшебез Ришат Җамалиевнның улы булып чыкты. Резедә апа белән Ришат абый 3 бала үстергән. Ике кызының үз тормышы. Берсе – 5, икенчесе 4 бала үстерә. Ә менә Ранис әлегә өйләнмәгән.

– Ранис киткәч, тормыш бөтенләй үзгәрде. Инде элеккечә тынычлап йоклау юк. Өстәл янына килсәм дә, улым тук микән, дип уйлыйм. Йөрәкнең ничек өзгәләнүен үзем генә беләм. Бер генә теләк – исән-имин әйләнеп кайтсын, – ди Резедә апа.

Җамалиевларның кияүләре махсус хәрби операция зонасына гуманитар ярдәм ташый. Бер яктан, улларына бирәсе бар әйберне җибәрә алуларына сөенсәләр, икенче яктан, кияүләренең гомере өчен дә борчылып торалар. Резедә апа әйтүенчә, кияүләре кайтып җиткәнче ут йоталар инде. Күптән түгел Ранис ялга кайткан булган.

Кайтуы да көтмәгәндә була аның. Ул чакта ике җизнәсе, энекәшләренә дип, районнан машина алып китә. Тәүлек эчендә барып җитәләр. Шунда аны ялга җибәрүләре билгеле була. Җизнәләре белән юлга кузгала. Егет, чәчәкләр күтәреп, өенә кайтып керә.

– Ике атна вакыт шулкадәр тиз уза икән. Сизелмәде дә. Улымны тәмле ризыклар белән сыйларга тырыштым. Инде хәзер посылкалар әзерлим. Әлегә кадәр улым алгы сызыкта иде. Хәзер башка җиргә чыгарганнар. Бераз гына тынычланып торам. Шөкер, хәбәрләшә алабыз. Әле менә беркөнне әтисе белән видеоэлемтә аша сөйләшкән. Анысына да сөендек, – ди Резедә апа.

Ришат абый да улы белән горурлануын яшерми. Ранис мин йөргән сукмаклардан йөри, ди ул.

– Хәрби хезмәтне шул якларда үттем. Менә хәзер улым да шунда барып эләкте. Дөрес тәрбия биргәнбез, дим. Батыр йөрәкле булуы – безнең өчен зур горурлык. Исән-сау яныбызга әйләнеп кайтсын иде, – ди ул.

Ранисның ике апасы да энеләре өчен изге теләктә тора. Рамилә белән Ранияне дә, җизнәләре Ришат белән Рәсимне дә берләштерә бу хәлләр. Алар бер уй белән яши, шуның белән йоклый, шуның белән уяна.

– Без әниебезне борчырга тырышмыйбыз. Күбрәк энем белән мин сөйләшәм. Икешәр атна алгы сызыкта вакытта тынычлыгыбыз югала. Энемнән хәбәр көтеп яшим. Чит номердан да «Ранис исән» дип язып җибәрәләр. Үзе дә хәбәр юллый, – ди Рания.

– Һәр әнинең улы исән-сау кайтсын иде. Хәбәрсез торудан да яманы юк. Шалтыратулар булмаса, яшәүнең яме бетә. Өмет өчен бер җылы сүз җитә, – ди Резедә апа.

Авыл фәлсәфәсе

ЧЫНЫГАМ ДИГӘЧ ТӘ...

Бураннардан соң авыл урамын күргән юк, бер әйләнеп кайтыйм әле, дип чыккан идем. Әмма беренче тыкрыктан соң ук күзем авыл башына, төгәлрәге, авыл бетеп, бераз баргач, юл кырында басып торган ярымшәрә кешегә төште. Ялгыш күрдем, ахрысы, киеме шундый төстәдер дип, кабат карадым (ерактан начаррак күрәм). Утыз-кырык градус булмаса да, салкын, җиле өтеп ала торган, ачы. Алдагы көннәрдә редакциябез фотографы Илдар Мөхәммәтҗанов Казан урамнарының берсендә шулай ярымшәрә кар көрәүче ир-атны фотога төшереп алган иде. Аңардан аермалы буларак, безнең геройда шорты түгел, чалбар, башына кимәгән (аяк киемен шәйләп булмады). Тик моңа кадәр бездә алай йөрүчене күргән юк иде. «Салган» баштан геройланып, өс киемнәрен салып аткан инде бу», – мин әйтәм. Бер кеше дә туктап утыртмаса, ике авыл арасында өшеп үләчәк.

Сирәк булса да, ул якка да, бу якка да техникалар үткәли. Берсе дә туктамый. Янымнан үтеп киткән техникалы танышым да, җилкәләрен сикертеп, аптыраулы кыяфәт ясап үтте. Түзмәдем, тракторы белән авыл башындагы болынлыкка кар ташучы күршебез Ришатны туктаттым.

– Танымадыңмы? Кем ул?

– Илфат. Безнең авылныкы.

Күңелем белән Илфатларны эзлим, әмма авылда андый исемлеләр калмады бугай инде дим. Минем аптыраулы кыяфәтне күреп, Ришат: «Дилбәр апайлар өен алган егет», – ди. Ул егетне, якыннан күрсәм, танып та, исемләп тә беләм лә. Истән генә чыгып киткән. Моңа кадәр аның турында гел уңай фикер генә ишетелә иде. Бу кыяфәте нәрсәне аңлата икән соң, дип уйланып кайтканда, аның белән якыннан аралашкан икенче күршеләребез Рәдифә белән Нурислам очрады.

– Илфатка нәрсә булган? – дим, хәл-әхвәлләрен сорашкач. Шунда ук аңлап алдылар.

– Яланөсме? – диләр.

– Әйе, – дим. – Эчми диләр иде бит аны, шул дәрәҗәдә эчәмени?

– Юк, исерек түгел бит ул, эчми. Бер дә күргәнең юк идемени? Шулай йөри бит ул. Чыныккан, – диләр.

– Ике авыл арасында юлында шундый кеше очраса, куркуыңнан егылып үләрсең, – мин әйтәм.

Авыл урамын әйләнәсе килү теләге югалды. Күңел авыл урамында мондый хәлне күрүгә әзер түгел иде, ахрысы. Чыныгам, чыныктым дигәч тә, урам уртасында ярымшәрә йөрү кайсы яктан карасаң да, килешә торган эш түгелдер инде. Бердән, ямьсез. Икенчедән, минем кебек, берәрсе бу йә исерек, йә «дөрес түгел» дип уйлап, органнарга шалтыратса, үзеңә дә күңелсезлек булып кайтырга мөмкин.

Без яшь вакытта салкын су белән чыныгуны пропагандалаучы Иванов системасы бар иде. Күпме кеше шуның белән фанатларча мавыгып, кар өстендә яланаяк йөрде (хәтта балалар бакчаларында да бер чорда бик популяр булды ул), баштанаяк ел әйләнәсе салкын су койды, кышын бәкеләрдә коенучылар да хәйран булды. Бер ел тирәсе үзем дә мавыктым салкын су кою белән. Әле аңа кадәр йөгереп кайтам. Чиләк белән салкын су коюның рәхәтлекләре иде! Чиләк күтәргән кулга салкын су тими кала, ул «үпкәли» иде... Кемнәрдер, кеше күрсен дип, кое, колонка төпләренә чыгып коенды (әле шуннан су алучылар тавыш та чыгара иде). Безнең кебек, үз ихатасында, кача-поса, коена торган урынга җәймәләр корып эшләүчеләр дә күп булды. Ул кышны мин көзге пальто һәм көзге аяк киеме белән чыктым. Аңа кадәр ангина белән җәфалана идем. Ул елны ник бер авырыйм! Хәзерге кебек техника заманасы түгел бит, район үзәгенә көн дә эшкә барырга, кайтырга кирәк – ярты гомер юлда техника көтеп үтә. Тик башлап-ташлап йөрүчеләргә файдасыннан күбрәк зыяны булды шикелле. Һәрнәрсәдә дәвамлылык кирәктер инде. Бер елдан йөгерүне дә, салкын суны да ташладым. Беренчесе – тезләргә, икенчесе башка, муен, аркаларга «файда» калдырды.

newrbfeet.ru

Кирәктер, бер чыныккач, бу егетләргә дә, кышын да үзләрен формада тоту өчен, ярым-йорты киенеп йөрү дә кирәктер. Тик урамга чыкканда өстенә җиңелчә ниндидер бер кием кисә, аннан гына эффекты әллә ни үзгәрмәс иде. Балтачның үзәгендә кыш буе фуфайка, кепкадан йөрүче бер абый бар иде, кушаматы «капитан» иде дип хәтердә калган. Ярымшәрә йөрмәсә дә, ничә еллар шул формада күрсәк тә, аның яныннан үткәндә җәяүлеләр дә, машинадагылар да борыла-борыла карый иде. Кайсыларыдыр әле кычкыртып сәлам дә бирә иде. Инде мәрхүм дип беләм.

...Шәһәргә ничектер, әмма авылга бер дә төс түгел бу, җәмәгать...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны **Сәгъдиев** Илдус Абдрахман улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – Татарстан Республикасы баш дәүләт торак инспекторы **Крайнов** Сергей Аркадьевич; эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга мөһим өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы эчке хезмәт полковнигы **Мөгыйнов** Рафаил Шәрип улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тоту бүлеге мөдире урынбасары **Вәлиев** Шамил Рәшит улы, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе баш киңәшчесе **Салихов** Далер Рамил улы; мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Казан шәһәре Идел буе районының «6 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Баклашова** Ольга Николаевна, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С. Пушкин исемендәге 9 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Гайфуллина** Татьяна Николаевна, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «3 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Гуляков** Анатолий Елизарович, «Мамадыш политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең производствода эшкә өйрәтү мастеры **Камалиев** Рәис Габделәхәт улы, Казан шәһәре Совет районының «Лицей – инженерлык үзәге» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Хәйретдинова** Венера Кәшфи кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисенең Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе башлыгы **Волков** Александр Иванович; югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыклары, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты баш киңәшчесе **Әпхәлимов** Азат Роберт улы, Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты баш киңәшчесе **Батухтина** Любовь Валерьевна, Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе **Галәветдинов** Алмаз Габдерахман улы, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе референты **Дәминов** Айрат Ринат улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләр белән эшләү бүлеге әйдәүче консультанты **Башкирова** Луиза Фоат кызы, Татарстан Республикасында Социаль өлкәгә һәм илнең икътисад тармакларына булышлык итү фонды директоры **Вәлиев** Илнур Рифат улы, «Газпром җылылык энергиясе Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галимов** Илдар Фаат улы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Биектау районы территориаль бүлекчәсе исәп һәм хисап бүлеге башлыгы **Галимова** Зөлфия Равил кызы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең гомуми гигиена кафедрасы профессоры **Галиуллин** Әфгать Нәбиулла улы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Ветераннар советы рәисе **Голицына** Людмила Александровна, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Мамадыш районы территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Каюмова** Фирүзә Сәүбән кызы, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Архитектура мирасын реконструкцияләү, реставрацияләү һәм архитектура нигезләре» кафедрасы мөдире **Надырова** Ханифа Габидулла кызы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Казан шәһәре территориаль бүлекчәсе республика бюджеты үтәлеше турында исәп һәм хисап бүлеге башлыгы **Усманова** Наилә Хәмидулла кызы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Нурлат районы территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Шәймәрданова** Нәфисә Исхак кызы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Чаллы шәһәре территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Чудасова** Ирина Владимировна; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Афанасьева** Флюра Васильевна, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Демидова** Любовь Сергеевна, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Круглое Поле поселогы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Сафина** Татьяна Владимировна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Зәй шикәре» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Чыбыклы» җитештерү комплексы идарәчесе **Агеев** Семен Семеновичка, «Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ферма мөдире (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Әхмәтов** Ринат Сәнәф улына, «Казан тегермәне» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте транспорт хезмәтенең йөктөягеч машина йөртүчесе **Борһанов** Рамил Сабит улына, «Васильев Леонид Николаевич» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Менделеевск районы) **Васильев** Леонид Николаевичка, «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 7 номерлы цехы теплица эшчесе (Татарстан Республикасының Зеленодольск районы) **Гобәйдуллина** Люция Нургали кызына, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Кузнецов** Николай Ивановичка, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сугым цехы җиһазларын төзекләндерү буенча слесаре-ремонтчысы (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Насыров** Дамир Дәүләтгәрәй улына, «Ирек» җитештерү комплексы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Хөсәенов** Фәрит Исрафил улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Галимҗанов** Алмаз Илдус улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең производство бүлеге башлыгы **Нуретдинов** Илгизәр Әнвәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Чаллы сәүдә базасы» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Латыйпова** Гөлсинә Ибраһим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Әлки муниципаль районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасының өстәмә белем бирү педагогы **Билалова** Гөлфия Шәүкәт кызына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 54 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Галиуллина** Альмира Лотфулла кызына, Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең «2 номерлы урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура һәм тормыш иминлеге нигезләре укытучысы **Галләмов** Эмиль Фәргать улына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «145 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Захарова** Мария Павловнага, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «М. Җәлил исемендәге 26 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Камалиева** Зөлфия Миңнур кызына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 89 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Костина** Наталья Александровнага, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Россия Герое А.В. Козин исемендәге 7 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Мухина** Татьяна Васильевнага, Казан шәһәре Яңа Савин районының «177 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Сәйфетдинова** Елена Валерьевнага, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «М. Җәлил исемендәге 26 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Ситдыйкова** Тамара Геннадьевнага, Казан шәһәре Вахитов районының «Советлар Союзы Герое А.С. Умеркин исемендәге 116 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Тюрина** Гүзәл Рафаэль кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәренең академик К.Ә. Вәлиев исемендәге 2 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Хәнәфиева** Роза Мәхмүт кызына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «22 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең география укытучысы **Латыйпова** Лилия Зәхрәп кызына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәренең 7 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Нурмөхәммәтова** Светлана Әгъдәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Актаныш муниципаль районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең өстәмә белем бирү педагогы **Мөхәммәдиев** Дилшат Сәгыйть улына **«Татарстан Республикасының халык укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Кайсыгызның кулы җылы?

ИКЕ БАЛАСЫ ФАҖИГАГӘ ЮЛЫККАН АЙГӨЛ:

«ТОРМЫШНЫҢ АСТЫ ӨСКӘ КИЛДЕ»

Мамадышта гомер итүче Айгөл һәм Наил Әхмәтҗановлар гаиләсенә узган елның 17 декабрендә зур хәсрәт килә. Әбиләрен туган көне белән котларга дип, Чаллыдан Мамадышка кайткан кызлар, кичәр юлда, Алабуга районының Костенеево авылы янәшәсендә юл һәлакәтенә очрый. 5 кеше утырган «Лада Гранта» туктап торган йөк машинасы астына керә.

Машина рулендә Әхмәтҗановларның олы кызы 25 яшьлек Ләйсән була. Янәшәсендә аның ире Айнур, артта Ләйсән белән аның йөргән егете, Айнурның апасы утырып барган була.

– Шундый рәхәт итеп сөйләшеп бардык. Матур теләкләр теләштек. Җырлар җырладык. Кияүгә иртәгесен эшкә булгач, балалар юлга кузгалды. Олы кызым 5 ел машина йөртә иде инде. Алда туктап торган машинаны күрмәгәннәр. Язмышка шулай язылган булгандыр, – ди Айгөл. – Бәрелүгә, машинадагы саклык мендәренең кияү ягындагысы ачылган, кызым ягындагысы – юк. Алиямнең бит сөякләре сынып беткән. Күп операцияләр ясадылар инде. 2 февральдә тагын берне ясыйсылары бар. Тән ярасы төзәлер дә ул, җан ярасы бар бит әле. Кызым сеңлесе өчен борчыла. Ләйсәннең хәле авыр.

Бу һәлакәттән Айнурның апасы бернинди җәрәхәтсез котыла. Ә менә 18 яшьлек Ләйсән ул чакта йоклаган була. Кыз ябык баш мие җәрәхәте ала һәм комага китә. Егете дә төрле җәрәхәтләр алып, хастаханәдә дәваланып чыга. Ә Ләйсән әле дә аңында түгел. Табиблар ышандыра, өмет бирә. Айгөл дә кызының уянып китәсенә бик ышана.

– Комада ятканда кызым вегетатив халәткә чыга алды. Бер күзен ача, кулларын селкетә башлады. Уянды дип сөенгән идек. Табиблар әле ашыкмаска куша. Миңа инде ул аңлый, ишетеп ята кебек. Без килгәч, тынычланып кала, киткәндә моңсулана шикелле. Керфекләрен дә селкетә төсле. Күңел гел яхшыга өметләнә. Әле бит яши генә башлаган бала. Егете дә акыллы. Кияүгә чыгу турында әйтә иде. Тик язмыш бөтенләй башкача хәл итеп куйды. Инде бер айдан артык хастаханә юлын таптыйбыз. Башта өч атна реанимациядә иде, хәзер госпитальгә күчерделәр, – ди Айгөл.

Табиблар, йә уянып китәр, йә инде гомер буе урында ятачак, дип әйтә икән. Наил белән Айгөл кызларының чирне җиңеп чыгасына ышана. Көн-төн бер теләктә алар – Ләйсәнебез генә уянсын! Белгечләр, мондый очракта бер ел вакыт кирәк, дип әйтә. Шуңа да дәвалауны туктатырга ярамый. Тернәкләндерү курслары үтәргә, хәрәкәтсез яткан аяк-кулларны эшләтергә кирәк.

– Бик авыр хәл бу. Йөгереп йөргән балаңның шулай итеп ярдәм көтеп ятканын күрү бик читен. Кадерләп үстергән ике кызыбыз бит алар. Алиям дә өзгәләнә. Аңа бик читен. Ирем дә авыруга сабышты, – ди Айгөл. – Ләйсәнне күрүгә үземнең дә күңелем тула. Тик түзәргә тырышам. Аның янында елау юк инде. Ишетеп ятар, дим. Әле менә бүген дә Ләйсән янына барабыз. Янына керү зур бәхет инде. Балачактагы кебек иркәлим үзен. Безнең өчен кечкенә кызчык әле ул. Күңел бәргәләнсә дә, сабыр итәм. Әмма йөрәк түзәмени?.. Ирем белән икәүләп төннәр буе елап чыгабыз. Догалар укыйбыз, Аллаһы Тәгаләдән, Ләйсәнебез савыксын иде, дип сорыйбыз.

Алия белән Ләйсән икесе дә Чаллыда яшәгән. Алия узган ел август аенда кияүгә чыгып, шунда күченә. Ләйсән исә Чаллыдагы бер уку йортына укырга керә. Әтиәниләре дә бик матур гомер итә. Тормышлары түгәрәк, балалар бәхетенә сөенеп кенә яшәгән чаклары була.

– Гаиләбезгә бу хәсрәт килүгә, бөтен туганнарыбыз яныбызда булды. Безнең өчен нишләргә дә белмәделәр. Якыннарым гына түгел, бөтен Мамадыш халкы хәл белешә. Гаиләбезгә килгән бу сынауны күтәрергә булышкан һәркемгә рәхмәт, – ди Айгөл. – Ул кичне мәңге онытмам. Тормышның астын өскә китергән көн булды ул. Тик бер нәрсә дә эшли алмыйбыз. Димәк, безгә моны күрергә насыйп булган. Табиблар ярдәм итәр дип өметләнәбез. Кызымның элеккеге тормышына кайтуын бик телим. Берәүгә дә мондый хәсрәт килмәсен.

Әхмәтҗановларның кызларына ярдәм итәргә теләүчеләр әтиләре Наил Вакыйф улы исемендәге **2202200856204761** номерлы Саклык банкы картасына акча күчерә ала. Карта **8 (939) 319-39-81** телефон номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Газетабыз турниры



Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖИҢӘРГӘ ДИП КИЛӘЛӘР

Лаешмы, Чаллымы? Әллә Теләче белән Әлмәтме? Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган көрәш бәйгесендә командалар арасындагы ярыш ел саен кызу була. Быел кемнәр өстен чыгар? Узган ел беренче урынны яулап, тарихи Кубокны үзләренә алып кайтып киткән Лаеш, алардан беразга гына калышкан Чаллы һәм өченче урынны алган Теләче егетләренең хәлен белештек.

«Келәм күрсәтер»

Лаеш районының Башкарма комитеты җитәкчесе, үзе дә күп еллар бил алышып, көрәштә зур уңышларга ирешкән Азат Нурмөхәммәтовның җавабы кыска булды: «Әзерләнәбез, җыеннар уздырдык, егетләрнең кәефе яхшы. Бөтен көрәшче дә бәйгегә җиңәргә дип килә. Калганын келәм күрсәтер». Дөрес, узган ел тәүге һәм әлегә бердәнбер җиңүен яулаган Лаеш командасында зур үзгәрешләр бар. Былтыр 90 килолы егетләр арасында батыр калган Раил Сәлахетдинов имгәнгән булуы аркасында быел бил алышмый. 130 килолы егетләр ярышында җиңүче булып танылган Радик Сәлахов исә туган ягы – Зәй районы данын яклый. Илмир Төхфәтуллин да рәсми ярышлардагы чыгышын туктатырга булды. Лаеш командасы составында башка үзгәрешләр дә бар дип беләбез. Кыскасы, былтыргы уңышны кабатлау җиңел булмаячак.

14 ел көтәләр

Командалар ярышында Чаллы егетләре 9 мәртәбә җиңү яулаган иде. Соңгы тапкыр 2010 елда ук. Чаллы командасы вәкиле Рамил Хисмәтуллин әйтүенчә, алар Җәлил турнирына җиңү өчен килә. Башка максат турында уйлап та карамыйлар.

– Әзерлек елдагыча. Чаллы командасы Җәлил турнирын ел да көтеп ала. Былтыр юбилей турнирына бик ныклап әзерләнгән идек. Нибары 0,5 балл аерма белән икенче урында калдык. Бу да начар түгел, билгеле. Бездә бит читтән килгән көрәшчеләр юк, үз көчебез белән бил алышабыз. Безнең командада Чаллыда яшәүче, монда эшләүче егетләр көрәшә. Шундый көрәшчеләрнең берсе Радик Сәлаховка безнең команда өчен көрәшергә тәкъдим итеп караган идек. Ләкин быел ул Зәй өчен чыгыш ясый, узган ел Лаеш өчен көрәшкән иде, – ди Рамил Хисмәтуллин. – Читтән көрәшчеләр җәлеп иткәнебез юк. Андый районнар бар инде ул. Шуның хисабына гына беренче баскычларда торалар да, көрәшчеләре китеп баруга, аска тәгәриләр. Ул көрәшчеләрне без дә чакыра алабыз. Ләкин бит ул очракта патриотизм турында сүз була да алмый. Көрәш аша Ватанга мәхәббәтне үз төбәге өчен көрәшүче батырларны күреп үскән балаларда гына тәрбияләп була.

Белми әйтмәс. Ул үзе дә 2009, 2011 һәм 2012 елларда безнең бәйгедә батыр булып танылды.

– Егетләргә Муса Җәлил истәлегенә уздырыла торган турнир турында әйтә киләбез. Яшерен-батырын түгел, бүген профессиональ көрәшчеләр акча ягын карый инде. Ул яктан башка ярышларда катнашу отышлырактыр. Ләкин дәрәҗә ягыннан караганда, Җәлил турниры – беренче урында. Егетләргә менә шуны аңлатырга тырышабыз, – ди Рамил Хисмәтуллин. – Җәлил турнирын откан көрәшче теләсә нинди табында утырырга хаклы ул! Бу минем сүзләр түгел. Бервакыт Түбән Камада уза торган Данил Галиев турнирында банкет залына ашарга кердем. Шунда мине бер абзый туктатты да: «Син кем?» – ди. Мин җавап бирергә өлгергәнче икенче берсе, бер зур абзый: «Бәйләнмә! Җәлилне откан егет ул, утырсын, ашасын», – диде. Ул сүзләрне мәңге онытмам. Егетләргә дә еш әйтәм аларны.

«Һәрберсе җиңә ала»

Теләче районы егетләре газетабыз бәйгесендә 3 мәртәбә – 1993, 2019 һәм 2020 елларда командалар ярышында җиңде. Узган ел алар өченче булды. «Әлбәттә, җиңәргә дип киләбез. Һәрвакытта яхшыга өметләнергә кирәк. Без генә түгел, башкалар да шулай. Республикада көрәш буенча, ким дигәндә, 10 көчле команда бар. Һәрберсе җиңә ала. Көндәшлек бик зур. Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында», – ди район башлыгы урынбасары, көрәшче егетләр белән һәр ярышка килүче Айрат Фәтхуллин.

Сүз уңаеннан, быелгы турнирда Теләче командасындагы иң көчле егетләрнең берсе, Җәлил бәйгесендә 8 тапкыр җиңү яулаган Ренас Кәлимуллин бил алышмый. «Әлегә авырып тора. Аңа да, башкаларга да сәламәтлек телим. Иң мөһиме – егетләргә матур итеп бил алышырга, үзебезнең көрәшебезне үстереп, милли гореф-гадәтләребезне күрсәтергә насыйп булсын», – ди Айрат Фәтхуллин.

ГАЛӘМЕҢ КЫЛГАН ГАМӘЛЕҢ

Мөнәсәбәт

Быел кәбисә ел гына түгел, карма (кешенең тәкъдирен билгеләп торган гамәлләр җыелмасы) елы да. Нумерологлар, астрологлар шулай ди. Гади итеп әйткәндә, һәр кем үзенә тиешлесен алачак. Игелек кылсаң, игелек, кырын эш белән мавыксаң, җәзасы әйләнеп кайтачак. Елны ничек уздырырга? Ялгышларны ничек булдырмаска? Бу хакта нумеролог Алсу ҖӘЛИЛ белән сөйләштек.

Гаделлек елы

Һәр елның үз энергиясе була. Нумерология ягыннан карыйк. 2, 0, 2, 4 саннарының суммасы 8 санын бирә. Ул гаделлек архетибына карый. Әлеге энергиянең нигезендә – сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше (причинно-следственные связи. – **Авт.**). Ягъни безнең тормышыбызда булган бер вакыйга да очраклы түгел. Алар барысы да – безнең элегрәк уйлаган фикерләребез, эмоцияләребез һәм гамәлләребезнең нәтиҗәсе. Ни чәчсәң, шуны урасың, кыскасы. Асылда, бу закон карма елында гына түгел, һәрвакыт эшли инде. Бу елны гына барысы өчен җавап тотабыз дигән сүз түгел. Ләкин сак булу зыян итмәс.

Елны ничек уздырырга?

Кешеләрне ничек бар, шулай кабул итәргә, яратырга өйрәнегез. Гомумән, тормышта үзең турында гына уйларга ярамый. Башкаларны да күрергә, аларга ярдәм кулы сузарга кирәк. Гамәлниятләр чиста булса, кармадан куркасы түгел. Чөнки тормыш сезнең юлыгызга да шундый кешеләрне чыгарачак. Әлбәттә, тормышта күңелсез вакыйгалар да була. Ләкин, ни генә булмасын, кешелек сыйфатын югалтмагыз.

Нишләргә һәм нишләмәскә?

– Низаглардан читтә торырга. Тормышта ак һәм кара гына булмый. Килеп чыккан хәлнең төрле яклары була. Шуңа күрә башкаларга карата сабыррак булырга өйрәник.

– Кешеләрнең ниндидер яман эшләрен күреп, аларны хөкем итәргә ашыкмагыз. Бу – бик агулы хис. Үзегез дә шундый ук хәлдә калмассыз дип кем әйтер?

– Үч алу турында да онытырга тәкъдим итәм. Аңлыйм, гадел булмаган мөнәсәбәт күрсәткән кешене урынына куясы килә. Ләкин карма законнары барысын да сездән башка да эшли. Мисал: сезгә кычкырдылар, сез котырасыз һәм җавапны да кычкырып кайтарасыз. «Сез – сезгә – сез – сезгә» боҗрасы барлыкка килә. Аны өзәргә кирәк.

ru.freepik.com

– Үзең яшәгән ил законнарына буйсынырга. Аларны үтәмәгән очракта ил законнары каршында да, карма законнары каршында да җавап тотасы. Бу елда сак булыгыз: барлык документларны да төгәл тутырырга, керемнәрне яшермичә, салымны түләргә.

– Башкаларны гаепләүдән тыелыгыз. Башта уйлагыз: болар барысы да нинди гамәлләрегез, нинди уйларыгыз аркасында килеп чыкты? Бернәрсә дә очраклы түгел.

Карманы чистартып буламы?

Карманы чистарту ул – мөмкин булганча башкаларга һәм үзеңә карата рәхимле гамәлләр кылу. Кемгәдер ярдәм итсәң, синең үзеңә дә ярдәм киләчәк. Шулай ук карма ярдәмендә үз теләкләреңне дә тизрәк чынга ашырырга мөмкин. Моның өчен «карма хезмәттәшлеге» ысулы кулланыла. Ягъни шундый ук теләге булган кешене табып, аңа хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә кирәк. Мәсәлән, сез фатир алырга телисез, ди. Моның өчен шундый ук хыялы булган кеше белән очрашырга һәм аңа булышырга кирәк. Ничек? Әйтик, риелтор киңәш итәргә, фатир сату турында игъланнар белән бүлешергә, мөмкинлек булса, матди ярдәм күрсәтергә. Иң мөһиме – чын йөрәктән аның хыялының тизрәк чынга ашуын теләү.

Карма ул – кылган гамәлләр генә түгел, уй-фикерләребез, ниятләребез дә. Алар барысы да тормышка тәэсир итә. Мисалларда карыйк.

1. Мин дустымның балаларын карап торырга ризалашам. Чөнки бу – яхшы гамәл. Ләкин эчемнән генә зарланам, аларны планнарым үзгәрүдә гаеплим.

2. Мин дустымның балаларын карап торырга ризалашам. Чөнки чын күңелдән ярдәм итәргә телим. Балалар белән бик күңелле итеп вакыт уздырам.

Бер үк эш, әмма ниятләре төрле. Димәк, нәтиҗә дә төрле була.

P.S. Язма эзотерик күренешләрне пропагандалау максатыннан түгел, тасвирлау максатын күздә тотып әзерләнде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сүз уңаеннан

2024 ел кайсы йолдызлык вәкилләренә уңыш китерер? Кайбер астрологлар фаразларына караганда, барлык йолдызлыкларга да уңыш койрыгын тотарга ашыгасы, әмма кайберәүләргә бәхет аеруча елмаячак. Мәсәлән, Кучкарларга. Яңа мөмкинлекләр, карьерада үзгәрешләр көтәсе, ди. Шулай да уяулыкны югалтмаска куша йолдызлар. Уйланылмаган гамәлләр кылып ялгышырга түгел! Игезәкләрнең аралашу даирәсе киңәячәк. Шәхси тормышта да үзгәрешләр булмагае. Кешеләргә ачык һәм якыннарга карата ихлас булырга киңәш итә йолдызлар. Кызларның исә финанс ягы уңай якка үзгәрәчәк, ди. Белем алуга игътибарны арттырырга киңәш ителә. Сукояр, Балык, Кәҗәмөгез йолдызлыгы астында туганнарның да тормышында күңелле вакыйгалар булырга тиеш.

Ел студенты

БӘХЕТ ӘШЕ

Казан дәүләт энергетика университеты студенты, җәмәгать эшләрендә актив кыз белән аралашкач, аның чыннан да, әлеге җиңүгә лаек икәнлегенә инанасың. Сүзебез – «Ел студенты – 2023» бәйгесенең Гран-при иясе Гүзәл ГАЗЕТДИНОВА турында. Аның белән җиңү сере, республика яшьләре өчен мөмкинлекләр һәм аларны борчыган проблемалар хакында сөйләштек.

:: Ел студенты булу, республика премиясенә лаек булу өчен, уку алдынгысы гына булу җитмидер. Тагын нәрсә кирәк?

– Бәхет елмаю кирәк. Монда барысы да туры килергә тиеш: казанышларың да, тышкы кыяфәтең дә, фамилияң дә, җюриның кәефе дә. Кайчандыр мин «Ел студенты» бәйгесе финалына очраклы рәвештә генә килеп эләктем. Ул вакытта активист та түгел идем әле. Сәхнәдәге студентларны күргәч, күңелдә нидер кабынды һәм «мин дә шушы сәхнәгә менәчәкмен» дигән уй туды. Берничә ел шушы максат белән яшәдем, уку елларында моңа омтылдым. Әкренләп портфолиомны туплый тордым, башта кечерәк бәйгеләрдә катнаштым.

Берникадәр кыюлык һәм тәҗрибә җыйгач, күптәнге хыялым булган «Гран-при» номинациясенә гаризамны җибәрдем.

:: Яшьләр өчен Татарстанда мөмкинлекләр күп, дибез. Син бу мәсьәләдә республиканың нинди уңай якларын атар идең?

– Без, республика яшьләре, бәхетле, чөнки шундый матур һәм уңайлы төбәктә яшибез, аның мөмкинлекләреннән файдалана алабыз. Әйтик, хәзер яшь белгечләрне дә эшкә, стажировкаларга бик теләп алалар. Җәмәгать эше алып барырга теләгәннәр өчен төрле яшьләр берләшмәләре, проектлар эшләп килә, аларда катнашып, үзеңне лидер буларак үстереп була. Сәнгать белән шөгыльләнергә теләүчеләр өчен дә барлык мөмкинлекләр бар, спорт турында әйтәсе дә юк – спорт объектлары чиктән ашкан.

Яшьләр министрлыгы бар яклап та бу мөмкинлекләрне арттыра бара: грант язу, волонтер булу, үз проектыңны башлау дисеңме, барысы өчен дә мәгълүмати ресурслар, ярдәм бар.

Шулай ук без «остаз» дигән сүзне яратабыз. Татарстанда уңышка ирешкән шәхесләр – яшьләргә үрнәк. Әйдәп баручы остазлар булса, уңышка ирешү җиңелрәк. Алар минем дә булды, хәзер инде үзем тәҗрибәм белән уртаклашам, яшь активистларга ярдәм итәм. Минем өчен яраткан Татарстанымда яшәү, монда үсү һәм аның үсешенә үз өлешемне кертү – зур бәхет.

:: Бүген студентларны нинди проблемалар борчый?

– Нинди генә җәмгыятьтә яшәсәк тә, проблемалар һәрвакыт булачак. Алар булмаса, без алга таба үсмәс идек. Иң мөһиме – коллектив белән бергәләп чишү, һәм проблеманы чишәм дип, кемгәдер каршы бармау. Мине борчыган проблема ул – кайбер яшьләрнең «урам» тормышы алып баруы, мөмкинлекләр белән кызыксынмавы, тормышта максатлары булмау. Ничек кенә тырышсаң да, бу категория яшьләрне кызыксындыру авыр.

:: Син бит әле югары уку йортлары арасында үтә торган «Яз гүзәле» матурлык һәм талант конкурсын да җитәклисең. Төрле проектлар уйлап табуың да сер түгел. Шундыйларның берсе – «Татар телендә онлайн матурлык марафоны» проекты. Аның турыда тәфсилләбрәк сөйлә әле.

– Татар телен үстерү өчен мәйдан (платформа) булдырасым килде. «Яз гүзәле» проекты кысасында онлайн матурлык марафонын үткәрдек. Ул быел да булачак. Марафонда бәйгегә гариза биргән һәрбер кыз катнаша ала. Өй эшләре итеп бирелгән биремнәр нәтиҗәсе буенча финалистлар сайлап алыначак. Әлеге проект белән татар телен үстерүгә өлешебез керер, дип ышанам.

:: Һәр җирдә өлгер һәм актив. Бу сыйфатларың – гаилә тәрбиясеме?

– Мин Актаныш районы Такталачык авылында туып-үстем. Әнием – тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, әтием үз эшен алып бара. Әби белән бабай да – математика, физика укытучылары. Укытучылар династиясе миңа, иң яхшысы булу, «бишле»гә генә уку «чир»ен йоктырды. Әнием кешеләргә ярдәм итеп яшәргә, әтием җаваплы булырга, каршылыклардан курыкмаска өйрәтте.

:: «Ел студенты» бәйгесендә катнашырга теләүчеләргә ниләр киңәш итәр идең?

– «Җиңмәм инде мин», – дип уйласагыз да, катнашып карарга кирәк! Чөнки бу – зур тәҗрибә, үзеңә читтән карау, бәя бирү мөмкинлеге.

Шәхси брендыгызны булдырыгыз. Җиңү озак һәм җентекле хезмәт таләп итә. Үзеңә максат куярга, тырышырга һәм бәхет елмаячагына ышанырга кирәк.

:: Син хәзер дөньяның теләсә кайсы югары уку йортында белем алу мөмкинлегенә ия. Кайсы университетка укырга барасыңны беләсеңме әле?

– Әле бу хакта тәгаен бер фикергә килмәдем. Чит илгә барып уку, аннан тәҗрибә алып кайту да кызык. Үзебездә дә абруйлы уку йортлары бик күп.

Блиц-сораштыру

– Буш вакытың ничек уза?
– Спорт белән шөгыльләнәм, бассейнга йөрим, рәсем ясыйм.
– Шәһәрме, авылмы?
– Шәһәр.
– Алга таба нинди планнарың бар?
– Магистратураны тәмамлап, аспирантурага керергә исәп. Проект эшемне дәвам иттерергә, грант конкурсларында катнашырга, кияүгә чыгарга *(көлә)*.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2042 данә
Гомуми тираж – 11230 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 211

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+